**СОВЕТ ТАТАРСКО - ЯНТЫКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422634 с.Татар Янтык,
ул. Магазинная, д 31 а
Тел/факс 8-(378) -3-26-21

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАР ЯНТЫГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422634 Татарский Янтыгы авылы,
Кибет урамы, д 31а йорт
Тел/факс 8-(378) -3-26-21

**18 номер.** **2019 елның 1 ноябре**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Янтыгы авыл җирлеге составына керүче Татар Янтыгы торак пунктындагы гражданнар җыены карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татар Янтыгы авыл җирлеге составына керүче Татар Янтыгы торак пунктындагы гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Лаеш муниципаль районы Татар Янтыгы авыл җирлеге составына керүче Татар Янтыгы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2020 елда үзара салым акчасын 500 сум күләмендә кертергә..
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен урындагы мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:
   - Татар Янтыгы торак пунктында урам-юл челтәрен төзү, ремонтлау һәм карап тоту.
3. Әлеге карарны Татар Янтыгы авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында игълан итәргә: һәм http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.
4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Янтыгы авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: _________________ Р.М.Шамеев____

Татар Янтыгы авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе _________________ Р.М. Шамеев

.